КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 май г.Казань № 584

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктның 1 пунктчасында «Торак фондын мониторинглау» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» сүзләрен «торак фонды объектларын капиталь

ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглау дәүләт программасын булдыруның һәм үтәүне мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 14 – 20 нче пунктлар өстәргә:

«14. Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планы елга кимендә бер тапкыр түбәндәге нигезләрдә актуальләштерелергә тиеш:

1) күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау вакытларын һәм капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр хакын үзгәртү;

2) Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү;

3) Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күпфатирлы йортның уртак мөлкәтенә капиталь ремонт ясаудан баш тарту турында күпфатирлы йортта бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышы тарафыннан карар кабул итү;

4) күпфатирлы йортта бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышының күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясау турында карарының гамәлгә яраксыз булуын тану хакында суд карары үз көченә керүе;

5) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төре элек уздырылган булган һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә мондый хезмәтләрне кабат күрсәтү һәм (яисә) мондый эшләрне үтәү Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планы белән билгеләнгән срокта таләп ителми дип билгеләнгән;

6) капиталь ремонт үткәрелергә тиешле конструктив элементлар булмауга бәйле рәвештә күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырылган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләренең исемлеген кыскарту;

7) капиталь ремонт фондын булдыру ысулын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 7 өлешендә каралган нигезләрдә башкарылды;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк операторы тарафыннан капиталь ремонт эшләрен үткәрүгә комачаулау, шул исәптән күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы зат, йә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы зат тарафыннан мондый эшләр башкаруга подрядчы оешма тарафыннан капиталь ремонт эшләрен үткәрүгә юл куймау фактларын билгеләү тәртибен һәм Күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре һәм (яисә) күпфатирлы йорт белән идарә итүче зат һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы зат тарафыннан хезмәт күрсәтүләргә һәм (яисә) эшләр башкаруга күпфатирлы йорттагы һәм (яисә) күпфатирлы йортның төзелеш корылмаларына, инженерлык челтәрләренә, санитар-техник, электр, механик һәм башка җиһазларга подряд оешмасын кертмәүдә чагылган каршылык күрсәтүгә бәйле рәвештә күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару

мөмкинлеген билгеләү тәртибе (шул исәптән элек башланган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләр башкаруны тәмамлау) раслау турында» 2018 ел, 29 август, 729 нчы карары белән билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре һәм (яисә) күпфатирлы йорт белән идарә итүче зат һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы зат тарафыннан хезмәт күрсәтүләргә һәм (яисә) эшләр башкаруга күпфатирлы йорттагы һәм (яисә) күпфатирлы йортның төзелеш корылмаларына, инженерлык челтәрләренә, санитар-техник, электр, механик һәм башка җиһазларга подряд оешмасын кертмәүдә чагылган каршылык күрсәтүгә бәйле рәвештә күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару (шул исәптән элек башланган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләр башкаруны тәмамлау) мөмкин булмау билгеләнгән»;

9) йорт эчендәге газ белән тәэмин итү системаларын ремонтлау, лифтларны ремонтлау, алмаштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок биналарын ремонтлау эшләрен үткәрү срокларын үзгәртү.

15. Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына соңгы чорга күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча билгеләнгән срокны күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төрләре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләр кертү күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышының тиешле карары булганда, әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы 5 - 9 пунктчаларында каралган очраклардан тыш, гамәлгә ашырыла.

16. Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр әзерләү турында карарны, әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү өчен нигезләр булганда, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләре нигезендә вәкаләтле орган кабул итә.

17. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер ай эчендә Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнарына, шулай ук капиталь ремонт һәм торак фонды объектлары торышын мониторинглау дәүләт программасын формалаштыру һәм үтәүне мониторинглау дәүләт мәгълүмат системасына тиешле үзгәрешләр кертәләр.

18. Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып расланган Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтле органга Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

19. Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы муниципаль планнары нигезендә вәкаләтле орган Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көннән алып ике айдан да соңга калмыйча Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив

хокукый акты проектын төзи һәм аны раслау өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

20. Программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планы һәм Программаны гамәлгә ашыруның муниципаль кыска вакытлы планнары торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 8 өлешендә каралган тәртиптә урнаштырылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин